Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Чәчәкле авыл җирлеге Советы

# КАРАР

№ 44 04 .10.2021

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Чәчәкле авыл җирлеге Советының 2020 елның
12 октябрендәге 9 номерлы «җир салымы турында»
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советының 2020 елның 12 октябрендәге 9 номерлы «Җир салымы турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 1 пунктындагы 1.1 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«җирле үзидарә органнары, казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр милкендә булган, җирле бюджеттан финанслана торган җир асты байлыкларыннан файдалану белән шөгыльләнүче торак пунктлар җирләре категориясенә кертелгән җирләр».

1.2. 2 статьяның 1 пунктындагы 1.3 пунктчасында «0,2%» ны «0,4%» ка алмаштырырга.;

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

3. Әлеге карар Чәчәкле авылы торак пунктларында мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында://spasskiy.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында https://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырып, халыкка җиткерелергә тиеш.

Чәчәкле авыл җирлеге башлыгы: Р.Р. Фәисханов